РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2021 г. г. Альметьевск №33

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мелкәт һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмә хакында» 2014 елның 2 октябрендәге 402 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 2 октябрендәге 402 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 425 номерлы, 2015 елның 7 августындагы 484 номерлы, 2020 елның 23 июнендәге 382 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче кушымтада 2 бүлекнең 2.3 пунктындагы «в» пунктчасында «оешмалар)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен естәргә;
- 1 нче кушымтада 4 бүлекнең 4.5 пунктында «оешмалар),» сүзеннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU)» һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Заказ № 2625